СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.04.2026 № 9/2

На №__________от______________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районы халкының сәламәтлеген ныгыту буенча күрелә торган чаралар турында

«Район халкының сәламәтлеген ныгыту буенча күрелә торган чаралар турында» мәгълүматны тыңлап, муниципаль район Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Район халкының сәламәтлеген ныгыту буенча күрелә торган чаралар турында» мәгълүматны исәпкә алырга.

2. «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 27 мартындагы 287 номерлы карары һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган программалар нигезендә район халкының сәламәтлеген ныгыту буенча профилактик эшне дәвам итәргә.

3. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә даими рәвештә «Тукай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе уздырган профилактик декадниклар тематикасы буенча мәкаләләрне яктыртуны тәкъдим итәргә.

4. «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү коплекслы үзәге белән пациентларны диспансерлаштыруга, 65 яшьтән һәм аннан өлкәнрәк затларга җентекле диспансерлаштыруга, шулай ук озак вакытлы карау системасы буенча диспансер күзәтүенә алып бару буенча уртак эшне дәвам итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны социаль сәясәт, инфраструктура үсеше һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе

К.Р. Нәҗмиев